# КАРАР

**2023 елның 6 августы** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында «Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Каенсар авылында гражданнар җыенына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә Каенсар авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 6 августында түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Каенсар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Каенсар авылының Мәктәп урамы, 1 Май урамында вак таш белән капланган юлларны төзү һәм чокырларын ремонтлау(вак таш сатып алу, ташу, салу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 271 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 160.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 160 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар җирлеге Каенсар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Каенсар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Каенсар авылының Мәктәп урамы, 1 Май урамында вак таш белән капланган юлларны төзү һәм чокырларын ремонтлау(вак таш сатып алу, ташу, салу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Каенсар авыл җирлеге
башлыгы И.Х.Исхаков